| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| от 20 сентября 2022 г. | № 10 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында»;

б) карарның 1 пунктында «Муниципаль берәмлек башкарма комитеты» сүзләрен «муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 карары 1 нче кушымтасының

исемендә «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга;

г) Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 карары 2 нче кушымтасының «муниципаль берәмлекнең башкарма комитетында (туганнары булмаган) сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы, Заварыкин урамы, 36 йорт, Зеленая урамы, 7 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы И.Н. Сушкова